Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«09» апрель 2024 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Элек расланган гражданнар җыенында чыгарылган мәсьәләгә үзгәрешләр кертергә:

- «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 12 октябрендәге 5 номерлы карары,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Түбән Чаллы авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 12.10.2023 ел, № 6 карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Сез 2024 елда Иске Чаллы авыл җирлеге Түбән Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000,00 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Н. Захаров

Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров